**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2019 Балык Бистәсе штп. № 14пи

Торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында” 96пи номерлы карарына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын расларга (теркәлә).

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 19 ноябрендәге 230пи номерлы карары белән расланган торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында” 107пи номерлы карарының 37 пунктын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 25 гыйнварындагы
14 пи номерлы карарына
кушымта

**Торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: торакка мохтаҗ физик затлар (алга таба – гариза бирүче, мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәт күрсәтүне башкаручы – Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Бүлекнең урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән тәгаенләнә.

Белешмә телефоны: (884361)2-22-96;

Үтү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. . Балык Бистәсе муниципаль районының (алга таба – муниципаль район) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтының адресы: www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук Бүлекнең урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны эченә алган Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

2) муниципаль районның Интернет челтәрендәге www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. рәсми сайты ярдәмендә;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында;

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында.

5)Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазь йөрткечтә, электрон почта буенча электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номер белән Торак кодексы (РФ законнары җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 кисәк), 14 маддә) (алга таба – РФ ТК);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

1995 елның 12 гыйнварындагы “Ветераннар турында” 5- ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 5- ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 16.01.1995, № 3, 168 маддә);

1995 елның 24 ноябрендәге “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 181 – ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181 – ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563маддә);

1996 елның 21 декабрендәге “Ятим балаларга һәм ата-аналар кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында” 159 – ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 159 – ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 23.12.1996, № 52, 5880 маддә);

Татарстан Республикасының 2004 елның 27 декабрендәге “Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында” 69-ЗРТ номерлы Законы (алга таба – ТР ның 69-ЗРТ номерлы Законы ) (Татарстан Республикасы, № 259-260, 31.12.2004);

Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге “Татарстан Республикасы дәүләт торак фондының һәм муниципаль торак фондының торак биналарын социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарга бирүгә аларның хокукларын тормышка ашыру турында” 31–ЗРТ номерлы законы (Татарстан Республикасы, № 144, 20.07.2007);

ТР МК ның 2007 елның 18 декабрендәге “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-аналар кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук беркетелгән торaклары булмаган ятим балалар һәм ата-аналар кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны торак белән тәэмин итү буенча чаралар турында” 732 номерлы карары (алга таба – ТР МК ның 18.12.2007 № 732 карары) (ТР МК ның карарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары ҖЫЕНТЫГЫ, 11.06.2008, № 22, 0865 маддә);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендә XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) (Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://pravo.tatarstan.ru, 29.05.2015);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-8 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

Башкарма комитетның 2016 елның 29 февралендәге 07ри номерлы боерыгы белән расланган Бүлек турында Нигезләмә (алга таба – бүлек турында Нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 2015 елның 19 гыйнварындагы 03-ри номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5.Әлеге Регламентта Россия Федерациясенең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарының аерым категорияләре исәбе дигәннән исемлеге федераль норматив хокукый актлар һәм Татарстан Республикасы законы белән тәгаенләнгән гражданнарны торак белән тәэмин итү аңлашыла.

торак хокуклары объектлары – торак биналар:

торак йорт, торак йортның бер өлеше – бүлмәләрдән, шулай ук гражданнарның әлеге бинада көн итүе белән бәйле көнкүреш һәм бүтән хаҗәтләрен канәгатьләндерү өчен аталган ярдәмче файдаланудагы бүлмәләрдән торган индивидуаль-тәгаенләнгән бина;

фатир, фатирның бер өлеше – күпфатирлы йортта бер яки берничә бүлмәдән, шулай ук гражданнарның әлеге аерымланган бүлмәдә көн итүе белән бәйле көнкүреш һәм башка хаҗәтләрен канәгатьләндерү өчен аталган ярдәмче файдаланудагы бүлмәләрдән торучы андый йорттагы гомуми файдаланудагы бүлмәләргә туры үтү мөмкинлеген тәэмин итә торган структура ягыннан аерымланган бүлмә;

бүлмә – торак йортның яки фатирның гражданнарның торак йортта яки фатирда турыдан-туры яшәү урыны сыйфатында файдалану өчен аталган өлеше.

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында таләп аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты). Гариза ирекле рәвештә Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк буенча яки стандарт бланкка тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләп исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Торакка мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую | РФ ТК ның 51 маддәсе;<br>5-ФЗ номерлы федераль закон ;<br>ТР МК ның 18.12.2007 №732 карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Чиратта торучылар исемлегенә кертү турында карар<br>Хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат | РФ ТК ның 51 маддәсе;<br>5-ФЗ номерлы федераль закон;<br>ТР МК ның 18.12.2007 №732 карары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Торак комиссиясе каравына материаллар әзерләү – 19 көн.<br>Татарстан Республикасы буенча гаиләләр Реестрына кертү турында гариза бирүчегә хәбәр ирештерү – карар кергән вакыттан алып өч көннән артмаган срокта.<br>Комиссиянең чираттагы утырышын көтү срогы һәм Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды коммерцияле булмаган оешмасының административ процедураларны үтәү срогы хезмәт күрсәтү срогына керми.<br>Комиссия утырышлары айга бер мәртәбә уза. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгаручы яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә зарури | 1)Гариза (кушымта №1);<br>2) Шәхесне таныклаучы документлар;<br>3)Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә); | |

| | | |
|---|---|---|
| документларның, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле хезмәтләрнең, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу, шул исәптән электрон рәвештә алу, аларны бирү ысулларының тулы исемлеге | 4) Анкета;<br>5)Торак шартларын яхшырту өчен гариза бирүчене һәм аның гаиләсен учетка алу турында мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар (кушымта №2). | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге. | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) Хәрби хезмәт, шулай ук Россия Федерациясенең 1993 елның 12 февралендәге 4468-1 номерлы Законы белән күздә тотылган аңа тиңләштерелгән бүтән хезмәт узу чорлары турындагы мәгълүматлар (Кораллы Көчләрдән киткән (азат ителгән) гражданнар өчен);<br>2)йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органы тарафыннан бирелү очрагында);<br>3) торак бинаның яшәү өчен булган һәм гомуми мәйданын һәм бирелү вакытын күрсәтеп финанс-лицевой счеты (документ җирле үзидарә органы тарафыннан бирелү очрагында);<br>4) Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда эшләү чорларының дәвамлылыгы ( аларны исәпкә алып, тиңдәшле нигез буенча пенсиягә хокук билгеләнә һәм (яки) пенсия күләме исәпләнә) турында белешмә (Ерак Төньяк районнардан кайткан гражданнар өчен) ;<br>5) Гражданның даими яшәү урыны буенча аны | |

| | | |
|---|---|---|
| | билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында, гражданны алай дип тану датасын күрсәтеп, халыкның мәшгульлек хезмәте органнарының белешмәсе – эшсезләр өчен (Ерак Төньяк районнардан кайткан гражданнар өчен) ;<br>6)Күчемсез мөлкәткә һәм алар белән килешүләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган (хәзерге вакытта гамәлдәге) аның күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында белешмә (биш һәм аннан да артыграк балалары булып, бу балалар үз гаиләләрен кормыйча ата-аналары белән бергә яши торган күп балалы гаиләләр өчен) (ятим балалар, ата-аналар кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен);<br>7)Даими яшәү өчен торак бина алу (алмау), торак төзүгә (алуга) ссудалар яки субсидияләр яисә мәҗбүри күченүчеләр тарафыннан җуелган торак өчен компенсация алу турында белешмә (мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар өчен). | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерүләре муниципаль хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм мондый яраштыру муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең | Чираттагылар исемлеге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды белән килештерелә (алга таба – Дәүләт торак фонды) | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1)Тиешсез кеше тарафыннан документларны тапшыру4<br>2)Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3)Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда эчтәлекләрен бер мәгънәдә аңлатырга мөмкинлек бирмәүче искәртелмәгән төзәтүләр, җитди бозылулар булу;<br>4)Документларны тиеш булмаган органга тапшыру. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>1) Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны учетка кую хокукларын расламаучы документлар тапшыру;<br>2) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы булмаган күләмдә тапшырылган яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>3) Торак шартларының начараюына китергән гамәлләр кылынган көннән соң срок (биш ел) чыкмаган;<br>4)Дәүләт органыннан, җирле үзидарә органыннан яисә дәүләт органы, җирле үзидарә органы карамагындагы оешмадан ведомствоара запроска муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның (әгәр тиңдәшле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса) булмавын раслаучы җавапның | |

| | | |
|---|---|---|
| | килеп ирешүе. | |
| 2.10 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. . Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алынучы түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе, андый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәт алуга гариза тапшыру чират булганда – 15 минуттан артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Гариза Бүлеккә бирелә.<br>Дәүләт учреждениесе урнашкан бүлмә запрос рәсмиләштерү өчен өстәл һәм урындыклар, запросны тутыру үрнәкләре булган мәгълүмат стендлары һәм хезмәт алу өчен кирәкле документлар исемлеге белән җиһазландырылган | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора: | |

| | | |
|---|---|---|
| сыйфаты күрсәткечләре | 1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) Административ регламентны бозуга үзидарәлек хезмәткәрләре тарафыннан кылынган прецедентларның ( урынлы шикаятьләрнең ) булуы. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Электрон формада муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яки Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аркылы алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон документ формасында (http:// www. (http://uslugi.tatar.ru.) электрон адресы буенча җибәрергә мөмкин. | |

**3. . Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре**

3.1. . Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1.Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

4) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

5) документларны торак комиссиясе каравына җибәрү;

6)материалларны комиссия тарафыннан карау;

7)чиратта торучылар исемлегенә кертү турында карар проектын әзерләү, исемлекне формалаштыру;

8)гариза бирүчегә кабул ителгән карар хакында хәбәр итү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 3 кушымтада китерелгән (рус телендә).

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон буенча һәм (яки) Интернет-кабул итү бүлмәсе аша мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка сораулар буенча һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутыруда булышлык күрсәтә.

Әлеге пунктта тәгаенләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча күрсәтмәләр, консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аркылы яки почта аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында Бүлеккә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларын тапшыра.

3.3.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышанычнамә буенча гамәл кылу очрагында);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күздә тотылган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документлар күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүе, документларда кырып төзәтүләрнең, өстәп язуларның, сызылган сүзләрнең һәм искәртелмәгән бүтән төзәтүләрнең булмавын) тикшерүне.

Замечаниеләр булмаган очракта Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм аны махсус журналда теркәүне ;

гариза бирүчегә тәкъдим ителгән документларны алу турында документларны кабул итү датасы турында билге куеп, бирелгән керү номеры белән, муниципаль хезмәтне үтәүнең датасың һәм вакытын күрсәтеп, описьнең күчермәсен тапшыруны.

гаризаны карау өчен Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрүне.

Документларны кабул итүне кире кагу өчен нигез булган очракта Бүлекнең документлар кабул итүне алып баручы белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында гариза бирүчегә хәбәр итә һәм документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма рәвештә аңлатып документларны аңа кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Башкарма комитет җитәкчесе каравына җибәрелгән яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны тәгаенли һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гаризаны теркәгән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4.Торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданны мохтаҗ дип тану

3.4.1.Бүлек башлыгы кергән гаризаларны карый һәм документларны Бүлек белгеченә җибәрү яки торак шартларына тикшерү уздыру турында карар кабул итә.

Торак шартларын тикшерү турында карар кабул иткән очракта Башкарма комитет җитәкчесенең комиссия составын раслау хакындагы карар проектын әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза кергән (мөрәҗәгать ителгән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән документлар яки комиссия составын раслау турында карар проекты.

3.4.2. Башкарма комитет җитәкчесе комиссия составын раслый һәм карарны комиссия рәисенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар карар проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: комиссия рәисенә җибәрелгән карар.

3.4.3. Комиссия рәисе гражданның һәм гаиләсе әгъзаларының комиссия тарафыннан торак шартларын тикшерүне оештыра. Торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән формада учетка алу (кире кагу) турындагы нәтиҗә белән тикшерү акты төзелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар карарны алу вакытыннан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән тикшерү акты.

3.4.4. Бүлек белгече комиссиянең гражданны учетка кую (учетка куюны кире кагу) турында нәтиҗәсе нигезендә торакка мохтаҗ сыйфатында:

әгәр граждан мохтаҗ дип танылса, учет делосын формалаштыра;

әгәр граждан мохтаҗ түгел дип танылса, Башкарма комитет җитәкчесе янында хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хатны имзалый һәм тикшерү акты һәм нәтиҗә белән бергә гариза бирүчегә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар тикшерү үткәргән вакыттан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: делоны формалаштыру яки кире кагу турында хат.

3.5. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.5.1. .Бүлек белгече ведомствоара электрон бәйләнеш системасы ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгеләрне бирү турында запрос җибәрә:

1) Хәрби хезмәт, шулай ук Россия Федерациясенең 1993 елның 12 февралендәге 4468-1 номерлы Законы белән күздә тотылган аңа тиңләштерелгән бүтән хезмәт узу чорлары турындагы мәгълүматлар (Кораллы Көчләрдән киткән (азат ителгән) гражданнар өчен);

2)йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органы тарафыннан бирелү очрагында);

3) торак бинаның яшәү өчен булган һәм гомуми мәйданын һәм бирелү вакытын күрсәтеп финанс-лицевой счеты (документ җирле үзидарә органы тарафыннан бирелү очрагында);

4) Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда эшләү чорларының дәвамлылыгы ( аларны исәпкә алып, тиңдәшле нигез буенча пенсиягә хокук билгеләнә һәм (яки) пенсия күләме исәпләнә) турында белешмә (Ерак Төньяк районнардан кайткан гражданнар өчен) ;

5) Гражданның даими яшәү урыны буенча аны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында, гражданны алай дип тану датасын күрсәтеп, халыкның мәшгульлек хезмәте органнарының белешмәсе – эшсезләр өчен (Ерак Төньяк районнардан кайткан гражданнар өчен) ;

6)Күчемсез мөлкәткә һәм алар белән килешүләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган (хәзерге вакытта гамәлдәге) аның күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында белешмә (биш һәм аннан да артыграк балалары булып, бу балалар үз гаиләләрен кормыйча ата-аналары белән бергә яши торган күп балалы гаиләләр өчен) (ятим балалар, ата-аналар кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен);

7)Даими яшәү өчен торак бина алу (алмау), торак төзүгә (алуга) ссудалар яки субсидияләр яисә мәҗбүри күченүчеләр тарафыннан җуелган торак өчен компенсация алу турында белешмә (мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар өчен).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар документларның Бүлеккә килеп ирешкән көнендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турындагы запрослар.

3.5.2. Ведомствоара электрон үзара бәйләнеш системасы аша кергән запрос нигезендә мәгълүмат тапшыручыларның белгечләре соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы хакында хәбәр җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәр).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла: ведомствоара запросның документны һәм мәгълүматны бирүче органга яки оешмага кергән көннән соң биш көн дәвамында, әгәр ведомствоара запроска җавапны әзерләү һәм җибәрүнең бүтән сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән соратып алынган мәгълүматлар яисә кире кагу хакында хәбәрнамә.

3.6. Документларны торак комиссиясе каравына җибәрү

3.6.1.Килеп ирешкән мәгълүматлар нигезендә Бүлек белгече:

тәкъдим ителгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерүне;

гаиләнең учет эшен рәсмиләштерүне (барлык документларны аерым папкага комплектлау);

муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләрнең булуын тикшерүне. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта Бүлек белгече муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында нәтиҗә әзерли. Нәтиҗә учет делосына теркәлә;

гаиләнең учет делосын җәмәгатьчелек торак комиссиясе (алга таба – комиссия) каравына җибәрү.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе:комиссия каравына җибәрелгән учет делосы.

3.7. Материалларны комиссия тарафыннан карау

3.7.1. Комиссия сәркатибе гамәлгә ашыра:

кергән документларны өйрәнүне;

комиссиянең утырыш көнен тәгаенләүне;

комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр итүне.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар документлар кергән вакыттан алып ике көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына утырыш көне турында хәбәр итү.

3.7.2.Комиссия үзенең утырышында учет делосын карый һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую буенча кую яки кире кагу турында карар кабул итә. Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедура комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе:учетка кую яки аны кире кагу турында карар.

3.7.3.Комиссия сәркатибе комиссия карарын беркетмә рәвешендә рәсмиләштерә (2 нөсхәдә) һәм комиссия әгъзаларына кул куярга тапшыра.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куярга тапшырылган нәтиҗә.

3.7.4.Комиссия әгъзалары беркетмәне имзалыйлар һәм комиссия сәркатибенә юллыйлар.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары кул куйган нәтиҗә.

3.7.5. Комиссия сәркатибе беркетмәне гаиләнең учет делосы белән бергә Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедура карар кабул ителгәннән алып бер көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән комиссия беркетмәсе һәм учет делосы.

3.8.Чиратта торучылар исемлегенә кертү турында карар проектын әзерләү, исемлекне формалаштыру

3.8.1.Бүлек белгече комиссия тарафыннан учетка кую турында карар кабул ителү очрагында:

гариза бирүченең (никахта тормаучы гариза бирүченең) гаиләсе турындагы мәгълүматларны гражданнарның Татарстан Республикасы буенча Җыелма исемлегенә кертә (“Учет делосын теркәү” карточкасын булдыра, гариза бирүчегә учет номеры бирә);

“Гражданнарның Татарстан Республикасы буенча Җыелма исемлегендә яңа гариза бирүчеләрне гаиләләре белән теркәү турында” карар проектын әзерли (алга таба – карар).

Комиссия тарафыннан учетка куюны кире кагу турында карар кабул ителү очрагында Бүлек белгече учетка куюны кире кагу турында хат проектын әзерли (алга таба – хат) һәм аны килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар беркетмәнең һәм гаиләнең учет делосының килеп ирешкән вакытыннан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән карар (хат) проекты.

3.8.2.Бүлек башлыгы карар (хат) проектын яраштыра һәм Башкарма комитет җитәкчесенә имзалауга җибәрә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар алдагы процедура төгәлләнгәннән соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә кул куюга җибәрелгән килештерелгән (яраштырылган) карар (хат) проекты.

3.8.3.Башкарма комитет җитәкчесе карарны (хатны) имзалый һәм Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар алдагы процедура төгәлләнгәннән соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе:Бүлеккә юлланган кул куелган карар (хат).

3.8.4. Бүлек белгече карарны алгач документларны туплый (комплектлый) һәм Дәүләт торак фондына җибәрә.

Учетка куюны кире каккан очракта имзаланган хат, комиссия карарын теркәп, гариза бирүчегә почта аша җибәрелә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедура алдагы процедура төгәлләнгәннән

соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән документлар яки кире кагу турында хат.

3.8.5. Дәүләт торак фонды документларны кабул итә һәм гамәлгә ашыра:

торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме, җирләрнең дәүләт резервын формалаштыру тәртибе һәм файдалану өлкәсендә хезмәттәшлек турында төзелгән шартнамәләр нигезендә анализны һәм гомумиләштерүне;

учетка куелган гаиләләрнең (шулай ук никахта тормаган гариза бирүчеләрнең), шәһәрләр һәм районнар буенча бүлеп, реестрын формалаштыруны;

учетка куелган гражданнарның формалаштырылган реестрын яки учетка куюны кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп граданнарның бирелгән исемлекләрен Бүлеккә кире кайтаруны.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар документлар килеп ирешкәннән алып 15 көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: учетка кую турында карар яки сәбәбен күрсәтеп учетка куюны кире кагу.

3.9. Кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итү

3.9.1. Бүлек белгече Дәүләт торак фондыннан документларны алганнан соң торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую һәм Дәүләт торак фонды реестрына кертү турында яки учетка куюны кире кагу хакында гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар карар килеп ирешкәннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе:учетка кую яки учетка куюны кире кагу турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.10. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.10.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен КФҮ кә мөрәҗәгать итәргә хаклы.

3.10.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮ нең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮ тән документлар килеп ирешкәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсе КФҮ кә җибәрелә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектка виза салу тора;

2) билгеләнгән тәртиптә уздырылучы делопроизводствоны алып баруны тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарәнең ярты еллык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиешле) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләрне үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле бөтен сораулар да (комплекслы тикшерү) яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча сорау каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру максатларында һәм карарлар кабул иткәндә Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә тәкъдим ителә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән тәгаенләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесенең муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыруга җаваплы урынбасары, шулай ук Башкарма комитет белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структура бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән тәгаенләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылулар беленгән очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тартылалар.

4.4. . Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карамаган өчен җирле үзидарә органы җитәкчесе җаваплы була.

Җирле үзидарә органының структура бүлекчәсе җитәкчесе (урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне үзвакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы була.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен вазыйфаи затлар һәм бүтән үзидарәлек хезмәткәрләре Закон тәртибендә билгеләнгән җаваплылыкны тота.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтү органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, үзидарәлек хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. 5.1. Муниципаль хезмәтне алучы Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәрге тәртиптә Башкарма комитетка яисә муниципаль берәмлек Советына шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3)мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актлары тарафыннан тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүматларны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында кире кагуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу;

6) муниципаль хезмәт күрсәтүдә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7)Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору);

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә , 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, мөрәҗәгать итүчедән таләп итү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса.

11) 11) дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны бирүне мөрәҗәгать итүчедән таләп итү хаксыз яисә дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә түбәндәге очраклардан гайре:

а) дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны баштагы бирүдән соң дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

б) дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә баштагы кире

кагудан соң мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда яисә дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә һәм элегрәк тапшырылган документлар комплектына кертелмәгәннәрдә хаталарның булуы;

в) дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә баштагы кире кагудан соң яисә дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә документларның гамәлдә булу срогы чыгу яки мәгълүматның үзгәрүе;

г) дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә яисә дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә баштагы кире кагуда дәүләти хезмәт күрсәтүче органның, яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, дәүләт яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күздә тотылган оешма хезмәткәре ялгышының яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документ белән расланган фактын (билгеләрен) ачу, дәүләти хезмәт күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдә баштагы кире кагуда күпфункцияле үзәк җитәкчесенең яисә әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күздә тотылган оешма җитәкчесенең имзасы белән язма рәвештә шул турыда мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеһә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта, КФҮ аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтын (www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яисә югарырак торган органга (ул булса) кергән шикаять теркәлгән көненнән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдә кире кагуына карата шикаять яисә андый төзәтүләр срогын бозуга карата шикаять очрагында – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2)мөрәҗәгать итүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда), тору урыны турында мәгълүматларны – физик затның яисә мөрәҗәгать итүченең исеме, урнашу урыны турында мәгълүматларны – юридик затның, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрү өчен контакт телефоны номерын (номерларын), электрон почта адресын (адресларын) (булганда) һәм почта адресын;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматларны;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән мөрәҗәгать итүченең риза булмавына нигез булып торган дәлилләр.

5.5. Шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять муниципаль хезмәтне алган шикаятьне бирүче кеше тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 11.2 маддәсенең 8 өлешендә күрсәтелгәнгә таянып бирелә торган җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында мөрәҗәгать итүчегә 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 11.2 маддәсенең 8 өлешендә күрсәтелгәнгә таянып бирелә торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Кушымта №1

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

________________________________ -ка

гр..____________________________________________________________-дан(-тан),
(фамилия, исем, атасының исеме)

19____елдан ____________________________________шәһәрендә, поселогында, авылында

__________________________________________________________адресы буенча яшәүче,

## ГАРИЗА.

______________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкның сәбәпләрен күрсәтергә:
______________________________________________________________________________
гаиләнең бер әгъзасына торак мәйданы белән тәэмин ителешнең билгеләнгән дәрәҗәсеннән
______________________________________________________________________________
түбән булуы, санитар һәм техник таләпләргә җавап бирмәгән торакта яшәү,
______________________________________________________________________________
ярдәмче наем шартларында тулай торакта яшәү h.б.
______________________________________________________________________сәбәпле,

_____________________________________________________________________________--
Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак-көнкүреш комиссиясе тикшерүенә (фикер алышуга) торак мәйданы алуга (торак шартларын яхшыртуга) мине (гаиләмне) исәпкә кую турында минем үтенечне кертүегезне сорыйм.

19________елның_______________-нан(-нән)_________________________________ -да
оешманың исемен күрсәтергә
үземнең____________________________________ вазыйфасында эшләвемне хәбәр итәм.

Гаиләмдә__________ кеше (туганлык дәрәҗәсен, яшен күрсәтергә, кайсы вакыттан бирле яши)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**Кушымта:**

1. Авыл җирлеге Советыннан белешмә (гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин).
2. Йорт кенәгәсеннән өземтә (гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин).
3. Йортның техпаспортыннан өземтә.
4. Эш урыныннан белешмә.
5. Торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты ( оешма каршындагы ТКК яки профком тарафыннан төзелә).
6. Белешмәләр (торак мәйданы белән ташламалы тәэмин итүгә хокукны раслаучы документлар).
7. Паспортларның күчермәләре (фото, гаилә хәле, балалар, прописка).
8. Балигъ булмаган балаларның туу турында таныклыклары.
9. Милектә торак булуы яки булмавы турында БТИ (ТИБ) белешмәсе.
10. Милектә торак булуы яки булмавы турында Росреестрдан белешмә.

**Искәрмә:**

Шартлар, гаилә составы һәм эш урыны үзгәргәндә 1 айдан артмаган срокта мәгълүматларны ТКК нә хәбәр итргә..

Шәхси имза_____________________________________________________

«___»_____________________________20___ел

**Гариза бирүченең торак шартларын тикшерү**
**А К Ты**

Торак пункт __________________________________________________________________
(шәһәр, поселок, авыл һ.б.)
“___” ________________________20___ел

_________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________составындагы комиссия

_________________________урамында______номерлы йорт_____номерлы корпус____номерлы фатирда яшәүче гр._______ ____________________________________________-ның(-нең) торак шартларын
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
тикшерде һәм түбәндәгеләрне ачыклады:

1. ______________________________________________________________________
(җирле Советның,ведомствоның, торак-төзелеш кооперативының, хосусый милек хокукында) йорттагы биләгән торак мәйданы ____________кв.м булган _______бүлмәдән тора.
Бүлмәләрнең мәйданнары һәркайсы__________________________кв.м. __________бүлмәләр ___ катта_____________катлы йортта.

Йорт ______________________________________________________________________бүлмәләр
таштан, эре панельле, агач, тузган, авария хәлендә
________________________________________________. фатир _________________________
коры, юеш, якты, караңгы аерым, коммуналь

2. Йортның (торакның)төзекләндерелүе _________________________________
суүткәргеч, канализация,
__________________________________________________________________________________
кайнар су, җылыту (үзәктән, мич ягып), ванна бүлмәсе, лифт, телефон.

3. ____________________________________________ торакның яллаучысы,
фамилия, исеме, атасының исеме
торак-төзелеш кооперативы әгъзасы, йорт хуҗасы (кирәклесенең астына сызарга).

4. Әлеге мәйданда яшиләр:

| № п/п | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган елы | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайсы вакыттан бирле әлеге торак пунктта яши | Әлеге торакта кайчаннан бирле пропискада. Даими яки вакытлыча | Эш урыны.Вазыйфасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

5. Гариза бирүченең гаиләсе турында өстәмә мәгълүматлар_______________________
Бөек Ватан сугышы инвалиды, һәлак булган хәрби хезмәткәр, пенсинер гаиләсе, күп балалы гаилә һ.б.

_______________________________________________________________________________

6. Комиссия нәтиҗәсе (бәяләмәсе)
_______________________________________________________________________________

Комиссия әгъзаларының имзасы ____________________________________________
Торак -эксплуатация оешмасы башлыгы__________________________________
имза
Гариза бирүченең имзасы ______________________________________________

Кушымта № 2

**Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен учетка кую турында мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлеге**

1.Кораллы Көчләрдән азат ителгән гражданнар:

хәрби комиссариаттан хәрби хезмәтнең (хезмәтнең) гомуми дәвамлылыгы турында белешмә;

хәрби хезмәттән (хезмәттән) азат ителү турындагы, азат ителүнең нигезен күрсәтеп, боерыкның өземтәсе;

йорт кенәгәсеннән өземтә һәм финанс лицевой счетның күчермәсе;

торак шартларын яхшыртуга (торак бүлмәләр алуга) мохтаҗ сыйфатында учетка кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү буенча орган карарыннан өземтә;

торакның өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документның күчермәсе (андый хокук Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда);

2.ЧАЭС дә катнашкан гражданнар

гражданның федераль бюджет средстволары хисабына торак белән тәэмин ителүгә хокукын раслаучы документ;

йорт кенәгәсеннән өземтә һәм финанс лицевой счетның күчермәсе;

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ сыйфатында учетка кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү буенча орган карарыннан өземтә;

торакның өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документның күчермәсе (андый хокук Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда);

3.Мәҗбүри күченүче дип танылган гражданнар

гаиләнең һәрбер балигъ әгъзасына мәҗбүри күченүче таныклыгының күчермәсе;

Федераль миграция хезмәте территориаль органының даими яшәү өчен торак алу (алмау), торак төзүгә (алуга) ссуда яисә социаль түләү яисә җуелган торак өчен компенсация алу (алмау) турында белешмәсе ( РФ Хөкүмәтенең 10.04.2008 № 257 карары ред.);

йорт кенәгәсеннән өземтә һәм финанс лицевой счетның күчермәсе;

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ сыйфатында учетка кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү буенча орган карарыннан өземтә;

торакның өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документның күчермәсе (андый хокук Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда) (абзац РФ Хөкүмәтенең 15.10.2007 № 681 Карары белән кертелгән);

4.Ерак Төньяк районнардан каайткан гражданнар

йорт кенәгәсеннән өземтә һәм финанс лицевой счетның күчермәсе;

Ерак Төньяк районнарга яки аларга тиңләштерелгән урыннарга 1992 елның 1 гыйнварына кадәр килү фактын раслаучы документлар;

Ерак Төньяк районнардан яки аларга тиңләштерелгән урыннардан күченү сәбәпле торак субсидияләре алуга хокукы булган гражданнарның учетын алып бару буенча органның карарыннан өземтә;

Ерак Төньяк районнарда һәм аларга тиңләштерелгән урыннардагы хезмәт стажын раслаучы документларның күчермәләре;

пенсионер өчен пенсия таныклыгының күчермәсе;

I һәм II төркем инвалидлар, шулай ук балачактан инвалидлар өчен инвалидлык турында медик-социаль экспертиза дәүләт хезмәте органнары белешмәсе;

эшсезләр өчен гражданны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында, датасын күрсәтеп, гражданның даими яшәү урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнары белешмәсе;

торакның өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документның күчермәсе (андый хокук Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда)

## Биш һәм аннан да артык балалары булып, балалары үз гаиләләрен кормыйча ата-аналары белән бергә яши торган күп балалы гаилә категориясе буенча торакка мохтаҗ буларак аларны учетка кую турында мәсьәләне карау өчен зарури документларның исемлеге

1.Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза;
2. күп балалы ана таныклыгы;
3.гаиләнең һәрбер әгъзасының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләре (паспорт, туу турында таныклык, барлык битләре дә);
4.никахлашу турында таныклык (тулы булмаган гаиләгә кагылмый);
5.йорт кенәгәсеннән өземтә;
6. финанс-лицевой счет күчермәсе;
7.ир белән хатынның икесенә дә күчемсез милек объектларына хокук теркәү турында мәгълүматларның булмавы хакында хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;
8. ир белән хатынның икесенә дә теркәлү урыны буенча торакның булуы яки булмавы турында БТИ дан (ТИБ нан) белешмә.

## Ятим балалар, ата-аналары кайгыртуыннан мәхрүм булган балалар категориясе буенча торакка мохтаҗ буларак аларны учетка кую турында мәсьәләне карау өчен зарури документларның исемлеге

1.Торакка мохтаҗ буларак учетка кую турында Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза;
2. паспорт күчермәсе (барлык битләре дә);
3. юридик статусны раслаучы документларның күчермәләре (ата-аналарының үлеме турында таныклык күчермәләре, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында хөкем карары күчермәсе, ата-аналарны эзләү турында ЭЭБ нән белешмә, ата-аналарны хокуктан файдалануга сәләтсез дип тану турында хөкем карары, ата-аналарның булмавын раслаучы башка документлар);
4.теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә;
5.?
6. теркәлү урыны буенча финанс– лицевой счет күчермәсе;
7. теркәлү урыны буенча милкендә торак булмавы турында теркәү палатасыннан белешмә;
8. теркәлү урыны буенча милкендә торак булмавы турында БТИ дан белешмә.

**Искәрмә:**

* Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы документларны гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Кушымта №3

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы (рус телендә)



**Кушымта**
**(белешмә)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы һәм аны үтәүгә контрольне гамәлгә ашыручы җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **22-113** | Marat.Gafarov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | **23-956** | Rauf.Hasanov@tatar.ru |
| Бүлекнең әйдәүче белгече | **22-296** | Alsu.Musina@tatar.ru |